ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Әлеге Закон гражданнарның әхлаклылыгын, сәламәтлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында "Этил спирты, алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында" 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр билгели.

**2 статья**

Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен (сыраны һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, әче балны кертеп) ваклап сату рөхсәт ителми:

1) 22 сәгатьтән алып 10 сәгатькә кадәр, "Җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтү. Җәмәгать туклануы предприятиеләре классификациясе" ГОСТ 50762-2007 Россия Федерациясе илкүләм стандарты нигезендә "ресторан", "кафе", "бар" типларына кертелгән җәмәгать туклануы предприятиеләрендә җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтелгәндә алкоголь продукциясен ваклап сатудан, шулай ук пошлинасыз сату кибетләрендә алкоголь продукциясен ваклап сатудан тыш;

2) стационар булмаган объектларда урнашкан җәмәгать туклануы предприятиеләрендә;

3) күпфатирлы йортларда, шулай ук күпфатирлы йортларга өстәп төзелгән, кушып төзелгән, кушып-өстәп төзелгән биналарда урнашкан җәмәгать туклануы предприятиеләрендә, "ресторан", "кафе" типларына кертелгән җәмәгать туклануы предприятиеләреннән тыш;

4) 22 сәгатьтән алып 10 сәгатькә кадәр җәмәгать туклануы предприятиеләрендә ябык савытта (алып чыгу өчен);

5) сатып алучылар (кулланучылар) өчен керү урыны күпфатирлы йортның ишегалдыннан (ишегалларыннан) оештырылган “ресторан”, “кафе” типларына кертелгән җәмәгать туклануы предприятиеләрендә һәм күпфатирлы йортларда урнашкан сәүдә предприятиеләрендә.

**3 статья**

Әлеге Законның 2 статьясындагы 2, 3 һәм 5 пунктларында билгеләнгән чикләүләр әлеге Закон үз көченә кергән көнгә җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешмаларга һәм әлеге Закон үз көченә кергән көнгә сыраны һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, әче балны ваклап сатуны гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарларга карата әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң өч ай узгач кулланыла.

**4 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) “Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында” 2010 елның 22 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 11);

2) “Татарстан Республикасы территориясендә әзер продукция күләменең 15 процентган артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2011 елның 10 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10);

3) “Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында” Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында” 2013 елның 20 маендагы 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 5).

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елнын 6 марты
№ 10-ТРЗ